**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-20-08, факс: (8-84348) 2-21-73, Nsmsp.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2024 елның 24 нче сентябреннән № 37-140

2019 елның 15 ноябрендәге 50-166 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлегенең 15.11.2019 № 50-166 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының 31.05.2021 №10-32; 05.10.2021 №16-58; 29.06.2022 №20-73; 10.03.2023 №26-97; 17.08.2023 №29-111, 19.12.2023 №32-124; 28.03.2024 №34-128 карарлары редакциясендә) (алга таба-Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 13 статьясындагы 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль контрактлар муниципаль ихтыяҗларны сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә (Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый план-графикка кертелмәскә тиешле сатып алу очракларыннан тыш) төзелгән һәм расланган муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр закупкаларының план-графигы нигезендә төзелә һәм, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 72 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән очраклардан тыш, бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә түләнә.”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм интернет-телекоммуникация челтәрендәге Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Яңа Чишмә авыл
җирлеге Башлыгы В.М.Козлов